ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 16.09.2024 1389 КАРАР

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану турында карарлар кабул итү Тәртибен раслау хакында» 2024 елның 18 июненендәге 838 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 18 июненендәге 838 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетларына түләүләр буенча бурычны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану турында карарлар кабул итү Тәртибененә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 2 пунктындагы 2.2. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

««Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127 - ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, индивидуаль эшкуарның банкротлык процедурасын тәмамлау - бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә, күрсәтелгән Федераль закон нигезендә ул бурычын түләүдән азат ителә;»;

1.2. Тәртипнең 2. пунктындагы 2.3. пунктчасын төшереп калдырырга.

1.3. Тәртипнең 2 пунктындагы 2.6. пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

«2.6. суд приставы-башкаручы тарафыннан «Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясының 1 өлешендәге 3 һәм 4 пунктларда каралган нигезләр буенча башкару эшенең тәмамлануы һәм түләтүчегә башкару документын кире кайтару турында карар чыгарылганда, бюджетка түләүләр буенча бурычның барлыкка килү датасыннан биш елдан күбрәк вакыт узганда ;».

1.4. Тәртипнең 2.6.1 пунктындагы 2.6.1 пунктчасын төшереп калдырырга.

1.5. Тәртипнең 2 пунктның 2.6.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«2.6.2. банкрот дип тану турында гариза суд тарафыннан кире кайтарылганда яки банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турында эш производствосы туктатылганда;».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 13 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм басылып чыккан көннән үз көченә керә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары А.А.Томилинга йөкләргә.

Җитәкче Э.Р. Әхмәдиева

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 30C33C67746B0C8EA9DE00B6707B1433
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 19.10.2023 до 11.01.2025